Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль район Советы өченче чакырылышының
унтугызынчы утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль район Советы карары

2018 ел, 26 апрель № 139

“Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында” гы Питрәч муниципаль район Советы карары проекты турында

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль район Советы 2004 елның 28 июлендә кабул ителгән 45-ЗРТ номерлы “Татарстан Республикасының җирле үзидарәләре турында” гы Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертелүгә бәйле, Питрәч муниципаль районының уставының 92, 93, 94 нче статьяларына карата үзгәрешләр кертү турында карар кабул итте:

1. “Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында” гы карар проектын 1 номерлы кушымта буенча беренче укылышта кабул итәргә һәм фикер алышуга чыгарырга.

2. Түбәндәгеләрне расларга:

- “Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында” гы Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль район Советы карары проектына гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибен һәм гражданнарның аның турында фикер алуда катнашуны (кушымта № 2);

- “Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында” гы Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль район Советы карары буенча халык алдында тыңлаулар үткәрү тәртибен (кушымта № 3);

- “Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында” гы карар проектын халык алдында тыңлауларны 2018 елның 15 маена билгеләргә.

3. Халык алдында тыңлауларны үткәрү урыны итеп Питрәч муниципаль район Советының кече залын, халык алдында тыңлауларны үткәрү вакытын 15.00 сәг. билгеләргә.

4. “Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында” гы карар проектына кергән тәкъдимнәрне карау һәм гомумиләштерү, исәпкә алу өчен түбәндәге составта эшче төркем оештырырга:

Игнатьева Венера Алексеевна - эшче төркем җитәкчесе, Питрәч муниципаль районы башлыгы урынбасары;

Пашин Александр Александрович - эшче төркем әгъзасы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль район Советының җирле үзидарә органнары белән узара бәйләнеш, законлылык, хокук тәртипләре һәм регламент буенча даими комиссиясе рәисе.

Галәветдинов Искәндәр Зәйнетдинович - эшче төркем әгъзасы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль район Советының җирле үзидарә органнары белән узара бәйләнеш, законлылык, хокук тәртипләре һәм регламент буенча даими комиссиясе әгъзасы.

5. Эшче төркемгә “Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында” гы карар проектына караган төзәтмәләр һәм тәкъдимнәрне гомумиләштерегә һәм өйрәнергә, тәкъдимнәрне исәпкә алып карар проектын эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль район Советына кабат карарга кертергә.

6. Әлеге карарны “Вперёд” (“Алга”) район гәҗитендә бастырырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтына http://pestreci.tatarstan.ru урнаштырырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүгә алуны  Питрәч муниципаль район Советының җирле үзидарә органнары белән узара бәйләнештә, законнар, тәртип саклау һәм регламент буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Питрәч муниципаль районы башлыгы И.М. Кашапов

СОВЕТ ПЕСТРЕЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА ИНН 1633605407

Питрәч муниципаль район
Советы карарына кушымта № 1
26 апрель,  2018 ел  № 139

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль район Советы
карары

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы уставына
үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль район Советы 2004 елның 28 июлендә кабул ителгән 45-ЗРТ номерлы "Татарстан Республикасының җирле үзидарәләре турында" гы Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертелүгә бәйле, Питрәч муниципаль районының уставының 92, 93, 94 нче статьяларына карата үзгәрешләр кертү максатында түбәндәге карарны кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы уставына Питрәч муниципаль район Советының 2015 елның 21 маенда кабул ителгән 41/235 нче номерлы карары белән расланган (Питрәч муниципаль район Советының 2018 елның 17 январендә кабул ителгән 126 нчы номерлы, 2017 елның 13 июлендә кабул ителгән 100 нче номерлы, 2016 елның 5 февралендә кабул ителгән 31 нче номерлы, 2016 елның 27 декабрендә кабул ителгән 77 нче номерлы карары белән расланган үзгәрешләр белән), кушымтасы нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.
2. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт регистрациясе үтү өчен җибәрергә.
3. Әлеге карарны "Вперёд" ("Алга") район гәҗитендә бастырырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтына http://pestreci.tatarstan.ru урнаштырырга.
4. Әлеге карар рәсми бастырылган көннән көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүгә алуны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башлыгы урынбасарына йөкләргә.

Питрәч муниципаль районы башлыгы                    И.М. Кашапов.

Питрәч муниципаль район
Советы карарына кушымта
“___” ____________ № ____

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы уставындагы
үзгәрешләр һәм өстәмәләр

1. 1нче өлешнең 6 нчы статьясында “Район җирлеге әһәмиятендәге мәсьәләләр”:
   - 5 пунктагы “муниципаль район чикләренең җирле әһәмияткә ия булган, торак пунктлар чикләреннән тыш, автомобиль юлларының төзеклеге буенча” дигән сүзләрдән соң “юл хәрәкәтен оештыру” дигән сүзләрне өстәргә
     (2018 елның 30 декабрендә көченә керәчәк, 2018 елның 16 мартында кабул ителгән 10-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә);
   - 16 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
     “16) тупланыш буенча (шул исәптән аерым тупланыш) эшчәнлекне оештыруда һәм каты коммуналь калдыкларны чыгаруда катнашу
     (2019 елның 1 гыйнварында көченә керәчәк, 2018 елның 16 мартында кабул ителгән 10-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә);
   - 30 пунктка “(волонтерствога);” дигән сүзне өстәргә
     (2018 елның 1 маенда көченә кергән, 2018 елның 16 мартында кабул ителгән 10-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә);
   - 37 нче пунктагы “муниципаль районның авыллар арасындагы территория чикләрендәге планлаштырган элементларның исемнәре структурасы” дигән сүзләрне алырга.
2. “Район Башкарма комитеты” 49 нчы статьясының 2 пуктының 4 өлешендәге “Район чикләренең җирле әһәмияткә ия булган, торак пунктлар чикләреннән тыш, автомобиль юлларының төзеклеге буенча” дигән сүзләрдән соң “юл хәрәкәтен оештыра” дигән сүзләрне өстәргә.
   (2019 елның 1 гыйнварында көченә керәчәк, 2018 елның 16 мартында кабул ителгән 10-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә)

Питрәч муниципаль район
Советы карарына кушымта № 2
26 апрель, 2018 ел № 139

“Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы уставына
үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында” Питрәч муниципаль район Советы
карары проектына гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу
һәм алар буенча фикер алышуда катнашу
тәртибе

1. “Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында” Питрәч муниципаль район Советы карары проектына тәкъдимнәр Питрәч муниципаль район Советына 422770, Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Совет урамы, 18 нче йорт адресы буенча язмача формада, таблица рәвешендә, бирелгән үрнәк нигезендә төзәтмәләр кертелә:

| № п/п | Пункт, пунктчасы | Карар проекты тексты | Төзәтмә тексты | Төзәтмәне исәпкә алган текст | Төзәтмә кертүче автор (Ф.И. этисенең исеме, адресы, эш урыны, уку урыны) |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

2. Халык тыңлауларында катнашу һәм чыгыш ясау хокукларына ия булу өчен гаризаны 422770, Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Совет урамы, 18 нче йорт адресы буенча шәхси биреп яисә почта аша җибәреп була.

   Гаризалар, эш көннәрендә сәгать 8.00 дән 17.00 кадәр, халык тыңлаулары үтәргә 7 көн кала кабул ителә.
3. Гражданнарның тәкъдимнәре Питрәч муниципаль район Советының оештыру эшләре бүлегендә теркәлә һәм күрсәтелгән тәкъдимнәрне карау һәм йомгаклау өчен эшче төркемгә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы уставы проектына, кертү өчен бирелә.

Питрәч муниципаль район
Советы карарына кушымта № 3
26 апрель, 2018 ел № 139

“Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында” Питрәч муниципаль район Советы карары проекты буенча халык алдында тыңлаулар үткәрү тәртибе

1. Халык алдында тыңлаулар утырыш рәвешендә үтә.
2. Катнашучыларны теркәү халык алдында тыңлаулар башланырга бер сәгать алдан башлана.
   Оештыру комитеты, тыңлаулар була торган урынга, катнашырга теләүчеләргә, каршылыксыз үтүне тәэмин итәргә тиеш.
3. Тыңлауларда Район Башлыгы, Район Башлыгы урынбасары, Район Башкарма комитеты рәисе, Район Башлыгы билгеләгән башка затлар рәис була ала.
4. Рәис халык алдында тыңлауларны алып барырга һәм утырыш залында, сораулар буенча фикер алышулар вакытында килеп чыккан низагълар өчен, хокук бозучыны залдан чыгарып җибәрергә хокуклы.
5. Халык алдында тыңлаулар рәиснең, катнашучылар һәм каралачак мәсьәләләрнең асылы, тәртибе турындагы кереш сүздән соң башлана.
6. Беркетмәне рәсмиләштерү, кергән тәкъдимнәрне теркәү, рәиснең каралган мәсьәләләргә тәкъдимнәр кертү өчен халык алдында тыңлаулар утырышының сәркәтибе сайлана.
7. Каралачак мәсьәләләрнең эчтәлеген, тыңлауларда катнашырга теләк белдергән язмача гаризаларның санын һәм башка сорауларны исәпкә алып, утырышның эзлеклелеге һәм чыгыш ясау регламенты билгеләнелә.
   Рәиснең ризалыгы белән чыгыш ясауларның вакыты сузылырга мөмкин.
8. Рәиснең ризалыгы белән, халык алдында тыңлаулар утырышында катнашучылар, чыгыш тәмамланганнан соң, чыгыш ясаучыларга сораулар бирергә хокуклы.
9. Халык алдында тыңлаулар утырышының рәисе тәнәфес игълан итәргә һәм утырышны башка вакытка күчерүгә хокуклы.
10. Халык алдында тыңлауларда катнашу өчен, утырыш вакытында, тәртип саклау мәҗбүри булып тора. Халык алдында тыңлаулар утырышында катнашучыларның, тыңлаулар вакытында, катышырга, чыгышны өзәргә һәм комачауларга хокуклары юк.
11. Утырыш вакытында тәртип бозган катнашучыларны , утырыш рәисе, залда чыгарырга хокуклы
12. Халык алдында тыңлауларның тәкъдимнәре нәтиҗәләрен эшче төркем әзерли.

13. Халык алдында тыңлауларның тәкъдимнәре нәтиҗәләре, халык тыңлаулары үткәннән сон, 5 көннән дә соңга калмыйча Район рәсми сайтына, халык кулланышына куела.